**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

16.11.2019 № 376

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында» 2005 елның 8 ноябрендәге 320 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 19 ноябрендәге 305 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге 97 номерлы, 2011 елның 13 апрелендәге 171 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге 550 номерлы, 2014 елның 5 маендагы 310 номерлы, 2015 елның 2 ноябрендәге 640 номерлы һәм 2017 елның 18 сентябрендәге 557 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы 2 кисәге нигезендә:»;

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында нигезләмәдә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы 2 кисәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законы) 8 статьясы 2 кисәге» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «6 статьясы» сүзләрен «7 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары оешмалар вәкилләрен Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы составына кертү турында гаризаларны кабул итү тәмамланган көннән бер ай эчендә Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә раслана.»;

7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатларны алдан карау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Р.М. Гарифуллинны, Э.Р. Камалованы, О.В. Скворддяковны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Натфуллин Дамир Данил улын – Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасарын;

Нефедов Андрей Александровичны – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасарын;

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасарын.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ